ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№39 от «09» 02 2021 г.

Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче аерым категория гражданнарга торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында

Татарстан Республикасы Юстиция Министрлыгының 2021 елның 13 гыйнварендәге № 09/13-09/49 хаты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2005 елның 20 апрелендәге «Авыл җирендә, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары турында» 192 номерлы, 2005 елның 7 июнендәге «Авыл җирендә, Эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) эшләүче һәм яшәүче гражданнарның аерым категорияләренә торак һәм коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын бирү тәртибен раслау турында» 251 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чаралары түбәндәге категория гражданнарга күрсәтелә дип билгеләргә:

-Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының авыл торак пунктларында, эшчеләр поселокларында (шәһәр тибындагы поселокларда) яшәүче һәм эшләүче муниципаль белем бирү учреждениеләренең педагогик хезмәткәрләренә, мәдәният хезмәткәрләренә, мәгариф оешмалары җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына, әлеге белем бирү оешмаларының структур бүлекчәләре җитәкчеләренә һәм аларның урынбасарларына. Чыгымнарны компенсацияләү торак өчен түләү чыгымнарының, җылылык һәм яктырту чыгымнарының 100 проценты күләмендә торак мәйданын социаль норма чикләрен

0000010733

чикләмичә, коммуналь хезмәтләрне куллану нормативларын исәпкә алып, Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелә. Күрсәтелгән социаль ярдәм чарасы шулай ук пенсиягә чыккан, авыл җирлегендә урнашкан мәгариф оешмаларында, мәдәният учреждениеләрендә 10 ел эшләгән һәм анда яшәүче гражданнарга бирелә.

2. «Россия Федерациясенең аерым закон актларына социаль ярдәм чараларын исәпкә алу һәм камилләштерү өлешендә социаль ярдәм чараларын адреслылык принцибын үтәү һәм мохтаҗлык критерийларын куллану бурычларыннан чыгып бирү һәм камилләштерү өлешендә үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 декабрендәге 388-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә социаль ярдәм чарасын бирә торган вәкаләтле орган социаль тәэминатның Бердәм дәүләт мәгълүмат системасын (алга таба - ЕГИСО) куллану юлы белән һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм күләмдә, ЕГИСО операторы билгеләгән форматларга туры китереп, күрсәтелгән социаль ярдәм чарасын күрсәтү турында мәгълүмат бирүне тәэмин итә , дип билгеләргә.

3. Вәкаләтле орган авыл җирендә эшләүче һәм яшәүче муниципаль учреждениеләр белгечләренә коммуналь хезмәтләр өчен түләү буенча социаль ярдәм чараларын агымдагы елның 1 гыйнварына һәм гариза бирү датасына барлык дәрәҗәдәге бюджетларга салымнар һәм җыемнар һәм башка мәҗбүри түләүләр буенча үтәлмәгән бурычлар булмаганда күрсәтелә дип билгеләргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru) һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында (http://mamadysh.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең урынбасары М.Р.Хуҗаҗановка йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов